**Каралган**
МБ житәкчесе
_____ /Нәҗметдинова Л.Ә./
Беркетмә № 1
«25»август 2014 ел.

**Килешенгән**
«Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең УТЭБДУ
_____ /Сәгъдиева Г.Ф./
«25»август 2014 ел.

**Раслыйм**
«Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУ нең директоры
_____ / Әхмәдшина Л.М./
Приказ № 94
«27»август 2014ел.

Уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы

“Яңа Мәлкән ТГБМ” ГББМУ

Нәҗметдинова Ләлә Әсхәт кызы, икенче квалификацион категорияле укытучы

татар теле, 5 нче сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган
беркетмә № 1
« 25 »август 2014 ел.

2014 – 2015 нче уку елы

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

**5 нче сыйныфта** татар теленнән эш программасы түбәндәге документларны исәпкә алып төзелә:

1. 2012 нче елның 29 нчы декабреннән гамәлгә кергән“РФ дә Мәгариф турында”273 нче федераль кануны (“Закон об образовании в РФ” )
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турындагы кануны.
3. “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы.
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа.
5. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5-9 нчы сыйныфлар) / Төзүче-авторлар – М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов,– Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
6. ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының “Федераль дәүләт белем стандартлары нигезендә мәктәпләрдә татар телен һәм әдәбиятын укыту турында”гы 17291/14 №лы хаты (04.09.2014.)
7. ТРның гомумбелем мәктәпләре өчен чыгарылган базис уку-укыту планы (2012 нче ел)
8. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның 2014/15 нче уку елына уку-укыту планнары (25.08.2014 нче ел датасы белән чыгарылган 91 нче № лы боерык);
9. “Яңа Мәлкән ГБМУ” ның уку фәннәреннән эш программасын төзү турындагы локаль акты (Положение о рабочей программе учебного предмета, курса, дисциплины (модуля) МБОУ «Новомелькенская ООШ» Мензелинского муниципального района РТ)

### УКЫТУ ПРЕДМЕТЫНА ГОМУМИ АҢЛАТМА

Төп мәктәптә ана теле курсы белем бирү процессының предметара һәм аерым предмет эчендә куелган максатларын тормышка ашыруга йөз тота. Шуны искә алып, программада татар теленә өйрәтү эчтәлеге компетентлы якын килү принцибына нигезләнеп сайланды һәм тәртипкә китерелде. Әлеге принцип V–IX сыйныфларда коммуникатив, лингвистик һәм социомәдәни компетенцияләрне формалаштырырга һәм үстерергә ярдәм итә.

5 – 9 нчы сыйныфларда татар теленең төп эчтәлеге өйрәнелә, укучыларга татар теленнән системалы, фәнни яктан ныклы белем бирелә, уку эшчәнлегенең төп төрләре формалаша һәм үстерелә. Тәкъдим ителә торган материал татар теле тармакларының төп нигезен тәшкил итә.

Туган телнең граматик төзелешен, аның нечкәлекләрен һәм кулланылыш үзенчәлекләрен аралашу процессында дөрес кулланырга өйрәтү әлеге баскычта төп максатлардан санала. Татарстан Республикасында татар теленең дәүләт теле булуы, аның татар халкының рухи мирасын буыннан-буынга җиткерү чарасы икәнлеге, кешеләренең үзара аралашуында, шәхеснең формалашуында һәм дөньяны танып белүендә төп чыганак булуын укучыларга җиткерү бурычы да әлеге баскычта үтәлә. Бу баскычта татар теленең төп эчтәлеге өйрәнелә, укучыларга татар теле буенча системалы, фәнни яктан ныклы белем бирелә, уку эшчәнлегенең төп төрләре формалаша һәм үстерелә.

### Коммуникатив компетенция

Сөйләм эшчәнлегенең төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу һәм язма сөйләм) үзләштерелә. Беренче этапта укучылар укылган яки тыңланган текстның темасы, төзелеше һәм төп фикерен, жанрын ачыклый, текст буенча әңгәмә үткәрә, үз фикерен дәлилли, телнең орфографик һәм орфоэпик, лексик, морфологик, синтаксик нормаларын саклап, эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып, телдән яки язмача җиткерә. Телнең әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларга диалогик һәм монологик сөйләм оештыра. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзи. Төрле типтагы язма эшләр, шул исәптән

компьютер технологияләре кулланып, укучы диктант, изложение, сочинение һ.б. эшләр башкара. Татар сөйләм әдәбе нормаларын дөрес һәм урынлы куллана.

**Лингвистик компетенция**

Тел система һәм иҗтимагый-мәдәни күренеш буларак өйрәнелә. Татар теленең барлык бүлекләре буенча үзләштерергә тиешле түбәндәге төп теоретик мәгълүматлар карала:

1) татар теленең иҗтимагый-мәдәни роле; татар милли әдәби теле һәм аның орфографик һәм орфоэпик нормалары; телнең фонетик системасы һәм аның закончалыклары, комбинатор һәм позицион аваз үзгәрешләре; татар телендә аваз һәм фонема, транскрипция; иҗек, татар теленең иҗек калыплары; басым һәм аның төрләре; интонация һәм аның компонентлары;
2) сүз, аның лексик мәгънәсе; сүзләрнең мәгънә ягыннан төрләре; татар теленең сүзлек составы, аның ачык система тәшкил итүе; сүзләрнең килеп чыгышы, кулланылыш даирәсе һәм активлыгы ягыннан төркемләү; фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънә үзенчәлекләре; лексикография;
3) сүзләрнең мәгънәле кисәкләре, аларның төрләре, сүз ясалыш ысуллары;
4) мөстәкыйль сүз төркемнәренең лексик-семантик һәм морфологик-синтаксик үзенчәлекләре, бәйләгеч һәм модаль сүз төркемнәренең грамматик үзенчәлекләре, сөйләмдә кулланылышлары;
5) сүзтезмә һәм җөмлә, сүзләр һәм җөмләләр арасында бәйләнеш төрләре; җөмләнең аерымланган кисәкләре; җөмләләрне төркемләү принциплары; кушма җөмлә һәм аларның мәгънә ягыннан төрләре; туры һәм кыек сөйләм; текст, аның төзелеше; татар телендә тыныш билгеләре;
6) функциональ стильләр, аларның лексик-грамматик үзенчәлекләре.

**Этномәдәни компетенция**

Укучыларга телнең милли мәдәниятне чагылдыру формасы булуы аңлатыла. Тел чаралары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлекләре өйрәтелә. Тәкъдим ителгән текстлардан халык авыз иҗаты үрнәкләрен, тарихи лексиканы аеру, аларның төрләрен һәм мәгънәләрен ачыклау. Татар милләтенең дөньяны танып белүен чагылдырган төп төшенчәләр, аларның сүздә, сүз мәгънәсендә чагылыш үзенчәлекләре өйрәтелә. Татар халык иҗаты үрнәкләрендә сүзнең кулланылышы, төшенчәләрне бирү мөмкинлекләре анализлана.

Шулай итеп, татар мәктәбе өчен ана телен укыту программасы эшлекле якын килүгә нигезләнә һәм аны тормышка ашыру өчен кирәкле алшартларны күзаллап төзелә. Укучыларның сөйләм эшчәнлеге үсеше һәм шәхси үсеш-үзгәреше югарыда саналган компетенцияләрдә ачык чагыла: коммуникатив компетенция төркемендә өйрәнелә торган тел материалы аралашу күнекмәләре булдыру максатын күздә тотып бирелә, лингвистик компетенция төркемендә аралашу өчен кирәкле тел материалының төзелеше, структурасы, эчтәлеге тәкъдим ителә, социомәдәни компетенция төркемендә тел материалы халыкның мәдәниятен һәм тарихын чагылдыра торган билге буларак бирелә.

**Гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфында ана теленнән белем бирүнең максатлары:**

1) коммуникатив максат: укучыларны ана телендә иркен сөйләшергә һәм аралашырга, логик эзлекле итеп уйлый белергә, фикерне төгәл, ачык итеп җиткерә белергә өйрәтү; туган телнең аралашуда, рухи-әхлакый нормалар формалашуда һәм дөньяны танып белүдә төп чара булуын, аның эстетик кыйммәтен аңлату;
2) фәнни максат: татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз төзелеше һәм ясалышы турында теоретик мәгълүмат бирү;
3) тәрбияви максат: туган телгә ихтирам һәм ярату хисләре тәрбияләү; укучыларда гуманлылык хисләрен тәрбияләү; әти-әниләргә, инвалидларга, ятим балаларга шәфкатьлелек хисләрен тәрбияләү; матурлыкны күрә, тоя белергә өйрәтү; туган як табигатен яратырга өйрәтү; туган илең белән горурлану, аны саклау; сәламәт яшәүнең бер төре булган спорт белән кызыксындыру һ.б.

**Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган бурычлар:**

●укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең фонетик, график, орфографик, орфоэпик, лексик, сүз ясалыш, грамматик, стилистик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү һәм телне тулы бер система буларак күзаллауны булдыру;
●укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;
●телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;
● язма һәм сөйләмә тел чараларын дөрес куллана белергә, аларны чагыштыра һәм кирәклесен сайлый, бәяли белергә өйрәтү;
●татар әдәби теле нормаларын ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;
●телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын аңлату; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү;
●татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, аралаша-аңлаша белү;
●тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;
●текст һәм Интернет, электрон уку-укыту ресурслары, башка мәгълүмати чаралар белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны ала белү һәм шуны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
●укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын камилләштерү.

## Татар теле фәненең тоткан урыны

Татар теленнән эш программасы **5 нче сыйныфта** гамәлдәге базис план буенча һәм ТР Минзәлә муниципаль районы “Яңа Мәлкән төп гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль учреждениесенең 2014- 2015 нче уку елына укыту планы буенча 5нчы сыйныфта уку елы дәвамында 105 (атнага 3 дәрес) сәгатькә каралган.

Татар теле дәресләре Ч.М.Харисова, Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдиновлар төзегән татар телендә төп гомуми белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен татар теле дәреслеге” (Казан, “Татарстан китап нәшрияты”, 2012 нче ел) буенча укытыла.

Өстәмә әдәбият буларак Н.В.Максимов төзегән “5 - 7 нче сыйныфлар өчен дидактик материаллар” (Казан,”Мәгариф” нәшрияты, 2003 нче ел), Г.Вәлиева “6 нчы сыйныфта татар теленнән күнегүләр җыентыгы” (“Яңалиф” нәшрияты, 2006 нчы ел), Д.Г.Тумашева “ 6 нчы сыйныф өчен дидактик материаллар”(Казан, “Мәгариф”, 1999) кулланыла.

## Программаның эчтәлеге

**Тел** – кешеләрнең иң әһәмиятле **аралашу чарасы**. Туган тел турында әңгәмә. Тел кешене дус итә, бер-берсенә беркетә. Тел турындагы фән һәм аның тармаклары. Хикәяләү тексты язуның төп үзенчәлекләре. – 2 сәг.

**Башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау** (4 сәг.)

**Морфология** (24 сәг.)

I. Морфология турында гомуми төшенчә. Сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә. Исем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Килеш кушымчаларының язылышы.
Фигыль. Фигыль төркемчәләре: боерык һәм хикәя фигыльләр. Үткән, хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре.
Алмашлык. Зат алмашлыклары, аларның килешләр белән төрләнеше. Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнешендәге үзенчәлекләре.
II. Исемнәрне, фигыльләрне, зат алмашлыкларын танып белү, морфологик билгеләрен һәм җөмләдәге рольләрен аңлау, дөрес язу һәм сөйләмдә аларны дөрес куллану.

**Синтаксис һәм пунктуация (18 сәг.)**
I. Синтаксис һәм пунктуация турында гомуми төшенчә. Сүзтезмә. Сүзтезмәдә ияртүче һәм иярүче сүзләр. Аларны бәйләүче чаралар.
Җөмлә. Гади һәм кушма җөмләләр.Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре: хикәя, сорау,боеру җөмләләр. Тойгылы җөмләләр. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләнең иярчен кисәкләре.

II. Җөмләдән бәйләнешкә кергән сүзләрне парлап аерып чыгару. Сүзтезмәләрне танып белү. Аларда ияртүче һәм иярүче сүзләрне, бәйләүче чараны аера алу.

Хикәя, сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрне аера һәм дөрес интонация белән әйтә белү. Җөмләнең грамматик нигезен табу. Тиңдәш хәбәрле гади җөмләләрне кушма җөмләләрдән аеру. Бәйләнешле текст төзү.

Практик максатлардан чыгып, сүзләрне өлешчә морфологик, җөмләләрне синтаксик һәм пунктуацион яктан тикшерү.

**Фонетика. Орфоэпия һәм орфография**. (17 сәг.)

I. Фонетика, орфоэпия, орфография турында төшенчә. Сөйләм органнары. Авазларның ясалышы. Сузык һәм тартык авазлар. Сузык авазлар. Аларның саны һәм составы. Дифтонг турында төшенчә. Сингармонизм законы, аның ике төре. Сузыкларның кыскаруы. Тартык авазлар. Аларның саны һәм составы. Сөйләмдә тартыкларның үзгәреше (охшашлану, охшашсызлану, җайлашу). Тартык авазлар таблицасын төзү.

II. Авазларны ишетә һәм аера белү. Сузыкларны һәм тартыкларны дөрес әйтә белү. Сүзләрне дөрес басым белән әйтә һәм иҗекләргә бүлә алу.
Эш кәгазьләре: мәкалә язу.

I. Орфография турында гомуми төшенчә. Авазларны язуда күрсәтү. Алфавит. Сузык аваз хәрефләре. О, ө, ы, е хәрефләренең дөрес язылышы. Е,ё,ю, я хәрефләренең дөрес язылышы. Тартык аваз хәрефләре. Ч, ж, в хәрефләренең дөрес язылышы. [гъ] һәм [гъ] авазларының язуда бирелеше. [ж]һәм[й], [х]һәм [h], [н]һәм[ң],[w] авазларын белдерүче хәрефләрнең дөрес язылышы. Ь һәм ъ хәрефләренең дөрес язылышы. Сүзләрне юлдан юлга күчерү. Графика һәм орфография буенча үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау.

II. Сузык һәм тартык аваз хәрефләрен дөрес яза белү. Сүзләрне юлдан юлга күчерү кагыйдәләрен аңлау. Сүзләрне фонетик яктан тикшерә белү. Алфавиттан һәм орфографик сүзлектән дөрес файдалану.

**Лексикология һәм сөйләм культурасы**. (16 сәг.)

I. Лексика һәм сөйләм культурасы турында төшенчә. Татар теленең сүз байлыгы. Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре . Омонимнар. Синонимнар. Антонимнар. Фразеологик әйтелмәлә. Татар теленең чыгышы ягыннан сүзлек составы. Татар теленең кулланылыш өлкәсе ягыннан сүзлек составы. Татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составы. Сүзлекләр һәм алардан файдалану күнегүләре . Лексика бүлеген кабатлау һәм ныгыту.

II. Сүзләрне сөйләмдә дөрес куллана белү. Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләрен аера алу. Сөйләмне синоним, антоним һәм фразеологизмнар белән баету. Синонимнарның мәгънәви һәм стилистик яктан аермаларын күрү һәм аңлату. Синонимнардан файдаланып,тестттагы кабатланулардан арына белү. Сүзләрне лексик яктан тикшерә белү.
Аңлатмалы, фразеологик, татарча – русча, русча – татарча сүзлекләрдән һәм омонимнар сүзлегеннән файдалана белү.

**Уку елы дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** (7 сәг.)

**Формалаштырырга планлаштырган белем һәм күнекмәләр**

5 нче сыйныфта осталык һәм күнекмәләр укучыларның алдагы сыйныфларда алган осталык һәм күнекмәләренә өстәмә рәвештә, ә кайберләре берникадәр киңәйтелеп китерелә; димәк алардан да файдалана белү таләп ителә. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- тел берәмлекләрен тану, аңлау һәм анализлый белү күнекмәләре булдыру;
- сөйләм культурасын үстерү;
- туган телне саклау һәм үстерү өлкәсендә эшләргә теләк уяту;
- үз сөйләменә бәя бирү, камилләштерергә өйрәтү; татар теленең байлыгына һәм матурлыгына хөрмәт, зәвык тәрбияләү; төрле чыганаклардан мәгълүмат туплый белү, электрон чаралардан дөрес файдалана белү;
- туган тел турындагы белемнәрнең фәнни нигезен булдыру;
- сүзләрне фонетик яктан, төзелеше һәм сүз төркеменә мөнәсәбәте ягыннан тикшерү; ике баш кисәге дә булган җөмләләрне синтаксик яктан тикшерү; таныш модельләр нигезендә гади һәм кушма җөмләләр төзү;
- аерып күрсәтелгән таныш сүзнең мәгънәсен аңлату; 1-5 нче сыйныфларда алган мәгълүматларга нигезләнеп, кирәкле орфограммаларны табу, сүзләрнең язылышын, тыныш билгеләренең куелышын дәлилләү; җөмлә азагында тиешле тыныш билгеләрен һәм кушма җөмлә өлешләре арасында өтер кую;
- сузык һәм тартык авазлар арасындагы аерманы аңлату; о, ы, ә, я, ю, е, ё, в, к, г хәрефләре белдергән авазларга аңлатма бирү; ул хәрефләрне һәм шулай ук ъ,ь хәрефләрен дөрес язу, охшашланып яки чиратлашып килгән авазларны язуда дөрес белдерү;
- татар әдәби теленә рус теле, аның аша башка телләрдән кабул ителгән сүзләрне аеру, аларның мәгънәсенә төшенү; орфографик, татар теленең аңлатмалы һәм татарча – русча сүзлекләрдән файдалана белү; фразеологик әйләнмәләрнең мәгънәсен аңлау;
- сүзне мәгънәле кисәкләргә аеру һәм һәрберсенә аңлатма бирү, язуда шуларны шартлы билгеләр белән күрсәтү; ясалышы ягыннан сүз төрләренә аңлатма бирү, кушма сүзләрне дөрес язу;
- текстның темасын аеру һәм төп уйны аңлау. Гади план төзү; укыганның эчтәлеген төгәл, кыскартып яки киңәйтеп сөйләү. Сыйфатламалар кулланып, сочинениеләр язу. Сөйләм телендә һәм язма эшләрдә фикерләрне мөмкин кадәр төгәлрәк белдерү өчен, лексик синонимнардан урынлы файдалана белү;
- эш кәгазьләре төрләреннән хат, мәкалә һәм белешмә яза белү.

**Белемнәрне бәяләү системасы.**

Укучыларның гомуми грамоталылыгын тикшерү һәм үстерү өчен төрле характердагы диктантлар, шулай ук сүзлек байлыгын арттыру, бәйләнешле сөйләм үстерү, логик фикерләү дәрәҗәсен камилләштерү максатыннан сочинение һәм изложениеләр яздырыла.

**Язма эшләрнең күләме һәм аны бәяләү:**

| Сыйныфлар | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
|---|---|---|---|
| 5 | 4 | 5 | 4 |

**Диктантларны бәяләү**

1. Хатасыз яки бер тупас булмаган хата җибәргән эшкә (орфографик, яки грамматик, пунктуацион) “5”ле билгесе куела.
2. 2 хатага “4” ле билгесе куела.
3. 5 хатага “3” ле билгесе куела.
4. 12 хатага кадәр “2” ле куела.
5. 12 хатадан да артып китсә, “1” ле билгесе куела.

**Изложение һәм сочинениене бәяләү**

1. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса; җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә; хаталар булмаса яки 1 хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик) җибәрелсә, «5» ле куела.
2. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса, текстның башлам өлешендә төгәлсезлекләр китсә, 3 хата булса, «4» ле куела.
3. Текстның төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса, текстның башлам һәм бетем өлешләрендә төгәлсезлекләр китсә, 5 хата (мәсәлән, бер орфографик, бер грамматик, бер пунктуацион, ике стиль хаталары) изложениедә, 6 хата сочинениедә җибәрелсә, «3» ле куела.
4. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса, текстның күләме бик кечкенә булса, 12 хата китсә, «2» ле куела.

**Тестлаштыру формасындагы эшләрне бәяләү.**

90 - 100% башкарылган эш – “5”
75-90% башкарылган эш – “4”
50-75% башкарылган эш – “3”
50% тан түбән башкарылган эш – “2”

**Укыту-методик, мәгълүмати-техник чаралар белән тәэмин итү.**

**Харисова Ч.М. Татар теле: татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек - Казан: Татар.кит.нәшр., 2012**

**Укучылар өчен тәкъдим ителә торган әдәбият исемлеге:**


1. Харисова Ч.М.. Татар теле. Теория, күнегүләр, тестлар. - К: “Мәгариф” нәшрияты, 2006.
2. Шәмсетдинова Р.Р.. Татар теле. Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. - К: “Татарстан” китап нәшрияты, 2005.
3. Эш кәгазьләре үрнәкләре/З.В.Валиев.-Казан: Татар китап нәшрияты, 1999.
4. Максимов Н.В.. Урта мәктәптә татар теле укыту. Фонетика. Морфология. - К: “Мәгариф” нәшрияты, 2004.
5. Харисова Ч.М.. Татар теле. Анализ үрнәкләре. - К: “Мәгариф” нәшрияты, 2009.
6. Абдрәхимова Я.Х.. Татар теленнән мөстәкыйль эшләү өчен күнегүләр. 5-7. - К: “Мәгариф” нәшрияты, 2009.
7. Гыймадиева Н., Галләмова Р.. Татар теле. Кагыйдәләр җыентыгы. Анализ үрнәкләре. - Казан. “Гыйлем” нәшрияты, 2012.
8. Шакирҗанов Ә.Б.. Татар теле орфографиясенең кыен очраклары һәм укучыларның грамоталылыгын күтәрү юллары. Казан: РИЦ «Школа», 2009

9. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М.. Татар теле: кагыйдәләр, күнегүләр. Урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен. - Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2007.

**Белемнәрне тикшерү өчен контроль бәяләү материаллары:**

1. Хәбибуллина З.Н., Нәбиуллина Г.Ш.. “Диктантлар җыентыгы” Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 5-11 нче сыйныфлары өчен. Укытучылар өчен кулланма. - Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2006.
2. Максимов Н.В., Трофимова С.М., Хәмидуллина М.З. “Татар теленнән диктантлар һәм изложениеләр җыентыгы”. - Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2005.
3. Хәбибуллина З.Н., Гыйләҗев И.Г.. Хәбибуллина З.Н., Гыйләҗев И.Г.- Казан:“ Мәгариф” нәшрияты, 2003.
4. Гыймадиева Н., Баһавиева Р. “Контроль диктантлар һәм изложениеләр”. - Казан. “Яңалиф” нәшрият йорты, 2004.
5. Хәсәншина Р.Г. Методик ярдәмлек, 5 нче сыйныф, - К: Мәгариф, 2007 ел.
6. Бердәм республика имтиханына әзерләнү өчен ярдәмлек.Татар теле.-Казан: РИЦ “Школа”, 2008
7. Татар теленнән тестлар: Уку-укыту ярдәмлеге/Н.В.Максимов.-Казан: Мәгариф, 2008

**Укытучы өчен мәгълүмат һәм белем бирү чыганаклары**

1. “Мәгариф турында” Россия Федерациясенең Законы, 2013 (“Закон об образовании” Закон Российской Федерации)
2. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законы (6,7,10,32 статья).
3. Гомуми белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы (ТР Мәгариф министрлыгының 478 номерлы боерыгы, 05.07.2000 ел).
4. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5 – 9 нчы сыйныфлар). Т ө з ү ч е - а в т о р л а р ы : Г.Р.Галиуллина, М.М.Шәкүрова, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан, 2013 нче ел (үрнәк программа). ”Татар урта гомуми белем мәктәпләре өчен татар теленнән программа” 5-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел.
5. Диктантлар җыентыгы (төрле авторлар)
6. Изложениеләр җыентыгы (төрле авторлар)
7. Н.В. Максимов.Татар теленнән тестлар
8. Вәлиева Ф.С., Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы, К..: Раннур н-ты, 2000 ел.
9. Зәкиев М.З. Татар синтаксисы. К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2005.
10. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К.: “Мәгариф” нәшрияты, 2006.
11. Гыймадиева Н., Нуруллина Р.Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. К.: “Мәгариф”, 2007.
12. Максимов В.Н. Урта мәктәптә татар теле укыту. Фонетика. Морфология.К.: “Мәгариф” н-ты, 2004.
13. Максимов В.Н. Татар теленнән кулланма (синтаксис). Өченче китап. К.: “Мәгариф” н-ты, 2003.
14. Татар телендә тыныш билгеләре.
15. «Мәгариф» журналлары, “Ачык дәрес” газеталары

**Мәгълүмати-электрон ресурслар**

1. "Татар теле. 5-11", "Белем.ру" ҖЧЖ, 2009. Мультимедияле ярдәмлек.
2. Татар сайтлары: edu.tatar.ru; belem.ru; org.com

## Укыту процессының матди-техник тәэмин ителеше

I. Техник чаралар:
1. Проектор
2. Ноутбук
3. Интерактив такта

## Календарь-тематик план

**Сыйныф:** 5 нче сыйныф.
**Укытучы:** Нәҗметдинова Л.Ә.
**Сәгатьләр саны**: атнага – 3 сәгать (елына – 105 сәгать).
**Планлаштырылган контроль дәресләр**:
**Диктант язу –** 4 сәгать.
**Изложение язу** – 5 сәгать (икесе – контроль );
**Сочинение язу –** 3 сәгать + 1 өй сочинениесе.
**Административ к/эшләр**: 1

**Укыту-методик комплекты**
**Программа.** 1.Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана телennән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 933/14 нче №лы боерыгы белән расланган урнәк программа

2. "Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа" (5-9 нчы сыйныфлар) Төзүче авторлар: М.З.Зәкиев, Н.В.Максимов, Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2011 нче ел.

**Дәреслек**: Ч.М. Харисова , Н.В.Максимов, Р.Р.Сәйфетдинов. Татар теле: татар телендә төп гомуми белем бирү мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек - Казан: Татар.кит.нәшр., 2012

**Методик ярдәмлекләр**:

1. Н.В.Максимов " Татар урта белем бирү мәктәбенең 5 нче сыйныфы өчен дидактик материал, 2003.

**Календарь – тематик план**

| № | Дәрес темасы | Дәрес тибы | Дәрестә укучының эшчәнлек төре | Контроль эш төрләре | Теманы үзләштергәндә көтелгән нәтиҗәләр | Сәг. саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | план | факт |
| **I** | **Тел – аралашу чарасы – 2** | | | | | | | |
| 1 | Тел – кешеләрнең үзара аралашу чарасы | Катнаш | Тел белеме һәм аның тармакларын модельдә күрсәтергә | Мәкаль ләр язу | Телнең аралашу чарасы булуын аңлатырга. Сөйләмнең 2 төре (әйтмә, язма) | 1 | 01.09 | |
| 2 | Хикәяләү тексты язуның төп үзенчәлекләре. | Сөйләм үстерү дәресе | Хикәяләү текстын язуның 3 өлешен табу | Текст төзү | Хикәяләү текстын язуның планын төзү | 1 | 02.09 | |
| **II** | **Башлангыч сыйныфларда үткәннәрне кабатлау.(4)** | | | | | | | |
| 3 | Сүз төркемнәрен кабатлау | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Күнегүләр эшләү | Биремнәр үтәү | Сүз төркемнәре буенча алган белемнәрен ныгыту | 1 | 04.09 | |
| 4 | Фонетика бүлеген кабатлау | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Күнегүләр эшләү | Биремнәр үтәү | Фонетика буенча алган белемнәрне ныгыту | 1 | 08.09 | |
| 5 | Ясалышы буенча сүз төрләрен кабатлау. | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Мөстәкыйль эш | Ясалышы буенча сүз төрләре турындагы белемнәрне камилләштерү | 1 | 09.09 | |
| 6 | Лексикология бүлеген кабатлау | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Алган белемнәрне ныгыту | Биремнәр үтәү | Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау | 1 | 11.09 | |
| **III** | **Морфология (24)** | | | | | | | |
| 7 | Морфология. Сүз төркемнәре турында гомуми төшенчә. | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Модель төзергә өйрәнү | Практик эш | Морфология, орфография төшенчәләрен формалаштыру; сүз төркемнәре, аларның морфологик | 1 | 15.09 | |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | билгеләре<br>турында белемнәрне<br>актуальләштерү | | | | |
| 8 | Абстракт, конкрет исемнәр. | Яна материал<br>өйрэну | Модель төзергә өйрәнү | Практик<br>эш | | 1 | 16.09 | | |
| 9 | Исем, Ялгызлык һәм уртаклык<br>исемнәр | | Күнегүләр эшләү | Мөстә<br>кыйль эш | Исем, ялгызлык һәм<br>уртаклык исемнәр,<br>күплек<br>сандагы исемнәр,<br>исемнәрнең килеш<br>белән<br>төрләнеше<br>турындагы<br>белемнәрне<br>актуальләштерү | 1 | 18.09 | | |
| 10 | Берлек һәм күплек сандагы<br>исемнәр | | Модельне тулыландыру<br>һәм аны уку | Контроль<br>күнегү | Исемнәрнең берлек<br>һәм<br>күплек төре<br>турында<br>белемнәрне<br>системалаштыру | 1 | 22.09 | | |
| 11 | Исемнәрнең килеш<br>белән төрләнеше.<br>Килеш кушымчаларының<br>дөрес язылышы. | Белем һәм<br>күнекмәләрне<br>системалаштыру | Модельне тулыландыру<br>һәм аны уку | Диктант | Исемнәрнең берлек<br>һәм<br>күплек төре<br>турында<br>белемнәрне<br>системалаштыру | 1 | 23.09 | | |
| 12 | "Исем" темасын гомумиләштереп<br>кабатлау | Белем һәм<br>күнекмәләрне<br>системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне<br>зиһенгә алу, модельне<br>тулыландыру һәм аны уку | Күнегү<br>эшләү | Исем<br>алмашлыкларының<br>килеш белән<br>төрләнеше<br>турында белемнәрне<br>системалаштыру | 1 | 25.09 | | |
| 13 | **Аңлатмалы диктант.** | Сөйләм<br>телен<br>үстерү | Алган белемнәрне<br>ныгыту | Күнегү<br>эшләү,<br>сорауларга<br>җавап бирү | Исем буенча<br>белемнәрне<br>системалаштыру | 1 | 29.09 | | |
| 14 | Хаталар өстендә<br>эш.<br>Алмашлык. Зат | Белем һәм<br>күнекмәләрне<br>системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне<br>зиһенгә алу, модельне<br>тулыландыру һәм аны уку | Мөстәкыйль<br>эш | Алмашлыклар<br>турында<br>алган белемнәрне | 1 | 30.09 | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | алмашлыклары. | | | | системалаштыру | | | |
| 15 | Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, килешләр белән төрләнешендәге үзенчәлекләр | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | Күнегү эшләү | Исем алмашлыкларының килеш белән төрләнеше турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 02.10 | |
| 16 | Сорау алмашлыклары. . Килешләр белән төрләнеше. | Яңа материалны өйрәнү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | Күнегү эшләү | Сорау алмашлыклары турында белемне арттыру, аларның килеш белән төрләнешен күзәтү | 1 | 06.10 | |
| 17 | Сан. Саннарның төзелеш ягыннан төрләре | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыруһәм аны уку | Сөйләм телен үстерү | Сан. Саннарның төзелеш ягыннан төрләре турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 07.10 | |
| 18 | Сан алмашлыклары | Яңа белемнәр үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыруһәм аны уку | Контроль күнегү | Сан алмашлыклары турында төшенчә бирү | 1 | 09.10 | |
| 19 | Сыйфат һәм сыйфатланмыш | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | Күнегү | Сыйфат һәм сыйфат алмашлыклары турында белемнәрне системалаштыру. Сыйфатларның дәрәҗә буенча төрләнеше. | 1 | 13.10 | |
| 20 | **БСҮ. Изложение язу.** | Сөйләм үстерү | Алгоритм буенча эшләү | Изложение (“Тере гөл” Харисова Ч.М. , 2012, 185 б.) | Изложение (“Тере гөл” Харисова Ч.М. , 2012, 185 б.) | 1 | 14.10 | |
| 21 | **Изложениене язу. “Сыйфат”.** | Сөйләм үстерү | Алгоритм буенча эшләү | Изложение | Язу күнекмәләрен формалаштыру | 1 | 16.10 | |
| 22 | Синоним һәм | Белем һәм | модельне тулыландыру | Контроль | Синоним һәм | 1 | 20.10 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | антоним сыйфатлар | күнекмәләрне системалаштыру | һәм аны уку | күнегү | антоним сыйфатлар турында белемнәрне системалаштыру | | | |
| 23 | Фигыль һәм аның мәгънәләре | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | | Фигыль һәм аның мәгънәләре турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 21.10 | |
| 24 | Фигыльләрнең барлык–юклык төрләре | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | Контроль күнегү | Фигыльләрнең барлык – юклык формасы турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 23.10 | |
| 25 | Боерык фигыль | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | | Боерык фигыльләр турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 27.10 | |
| 26 | Хикәя фигыль, аның заман формалары | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | Контроль күнегү | Үткән, хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльләр. Фигыльнең барлык һәм юклык төрләре | 1 | 28.10 | |
| 27 | Шарт фигыль | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | Контроль күнегү | Шарт фигыль турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 30.10 | |
| 28 | “Фигыль” темасын ныгыту | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | Практик эш | Фигыльләрдә басымны билгели белү | 1 | 10.11 | |
| 29 | Рәвеш. Вакыт рәвешләре | Яңа белемнәр бирү. | Модель төзү. | Теорияне тикшерү | Рәвеш турында белемнәрне булдыру, тулылыандыру | 1 | 11.11 | |
| 30 | Урын рәвешләре 1 | Яңа материалны өйрәнү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | Теорияне тикшерү | Рәвеш турында белемнәрне булдыру, тулылыандыру | 1 | 13.11 | |
| 31 | Сәбәп-максат рәвешләре. | Белем һәм күнекмәләрне | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модельне тулыландыру һәм аны уку | Контроль күнегү | Антоним рәвешләр турында белемнәрне | 1 | 17.11 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | системалаштыру | | | системалаштыру | | | |
| 32 | Рәвеш темасын ныгыту | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | | Рәвеш алмашлыклары турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 18.11 | |
| 33 | Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау. Морфологик анализ ясау. | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | Контроль күнегү | Сүз төркемнәрен гомумиләштереп кабатлау | 1 | 20.11 | |
| 34 | **БСҮ. Контроль сочинение** | | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш | Бәйләнешле сөйләм эшчәнлеген үстерү | 1 | 24.11 | |
| 35 | **Контроль сочинениене язу "Әниләр – иң якын кешеләр".** | | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш | Бәйләнешле сөйләм эшчәнлеген үстерү | **1** | 25.11 | |
| **IV** | **Синтаксис һәм пунктуация (18)** | | | | | | | |
| 36 | Синтаксис һәм пунктуация турында төшенчә. Сүзтезмәдәге ияртүче һәм иярүче сүзләр, алардагы бәйләүче чаралар. Җөмлә. | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Контроль Күнегү-120 | Синтаксис һәм пунктуация турында төшенчә бирү. Сүзтезмә төшенчәсен формалаштыру | 1 | 27.11 | |
| 37 | Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре. Алар ахырында тыныш билгеләре. Хикәя җөмлә. | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Күнегүләр өстендә эш | Хикәя җөмләләр. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре | 1 | 01.12 | |
| 38 | Сорау җөмлә | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Күнегүләр өстендә эш | Сорау җөмләләр, Җөмлә ахырында тыныш билгеләре турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 02.12 | |
| 39 | Боерык җөмлә | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Күнегүләр өстендә эш | Боерык җөмләләр, Җөмлә ахырында тыныш билгеләре турындабелемнәрне системалаштыру | 1 | 04.12 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 40 | Тойгылы сорау,<br>хикәя, боерык җөмлә | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Контроль Күнегү-137 | Тойгылы җөмләләр, Җөмлә ахырында тыныш билгеләре турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 08.12 | |
| 41 | **Сайланма диктант** язу “Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләрен билгеләү” | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | | Сайланма диктант | Язу күнекмәләрен формалаштыру | 1 | 09.12 | |
| 42 | Хаталар өстендә эш. Гади җөмлә, кушма җөмлә | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү, Җөмлә тикшерү | Практик эш | Гади, кушма җөмләләрне аера белү, җөмләнең иясен һәм хәбәрен табарга өйрәнү. Схемаларны төзергә өйрәнү. | 1 | 11.12 | |
| 43 | Җөмлә кисәкләре. Җөмләнең баш кисәкләре. Җыйнак җөмлә | Катнаш | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Бирелгән җөмләләр не тикшерү | Җөмлә кисәкләре турында гомуми төшенчә. Ия һәм хәбәр җөмләнең баш кисәкләре. Җыйнак җөмлә. Җәенке җөмлә | 1 | 15.12 | |
| 44 | Зат алмашлыклары белән белдерелгән аныкланмышлар | Катнаш | Модельне тулыландыру һәм аны уку | | Ияргән һәм ияркән сүзләр турында мәгълүмат. Зат алмашлыкларының күплек формалары. | 1 | 16.12 | |
| 45 | Җәенке җөмләләр. | Катнаш | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Текс өстендә эш | Җөмлә. Җәенке җөмлә. Шартлы билгеләрне куллану. Җәенке җөмләләрне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерү тәртибе. | 1 | 18.12 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Морфологик-синтаксик анализ. | | | |
| 46 | **Контроль диктант**<br>“Җөмлә кисәкләре” | Контроль дәрес | | Контроль диктант. “Таң” (Харисова Ч.М. “Татар теле” 5 нче класс) 180 бит | Язу күнекмәләрен формалаштыру | 1 | 22.12 | |
| 47 | Хаталар өстендә эш. Ныгыту күнегүләре | Анализлау дәресе Җөмлә тикшерү | Җөмләтикшерү | Күнегүләр өстендә эш | Морфологик-синтаксик анализ, схемалар төзү, хат язарга өйрәнү. | 1 | 23.12 | |
| 48 | Кабатлау. Ныгыту күнегүләре | Катнаш | Җөмләтикшерү | Күнегүләр өстендә эш | Морфологик-синтаксик анализ, схемалар төзү | 1 | 25.12 | |
| 49 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү, Җөмлә тикшерү | Күнегүләр өстендә эш | Җөмләнең иярчен кисәкләре турындагы белемнәрне камилләштерү. Гади җөмләне тикшерү тәртибен формалаштыру. Аергыч. Сорауларга җавап бирү. | 1 | 12.01 | |
| 50 | Җөмләнең иярчен кисәкләре.<br>Тәмамлык. | Яңа белем үзләштерү | Җөмлә тикшерү | Күнегүләр өстендә эш | Тәмамлык. Кайсы җөмлә кисәген ачыклап килә. | 1 | 13.01 | |
| 51 | **БСҮ. Миниатюр изложение язу “Гади җөмлә».** | Сөйләм үстерү дәресе | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш (“Озак яшәүнең сере” Хари сова Ч.М. , | План төзеп эшләргә өйрәнү | 1 | 15.01 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2012, 186б.) | | | | |
| 52 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Хәлләр (урын, вакыт, рәвеш). | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү, Җөмлә тикшерү | | Җөмләнең иярчен кисәкләре турындагы белемнәрне камилләштерү. Гади җөмләне тикшерү тәртибен формалаштыру. Урын, вакыт хәлләр турында мәгълүмат туплау, аларны аерырга өйрәнү. Җөмләдә вазифаларын карау. | 1 | 19.01 | |
| 53 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Хәлләр (күләм, сәбәп, максат,). | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү, Җөмлә тикшерү | Контроль Күнегү-218 | Җөмләнең иярчен кисәкләре турындагы бе-лемнәрне камилләштерү. Күләм, сәбәп, максат хәлләрнең җөмләдә нәрсә белдереп киләләре. Схемалар белән эш. | 1 | 20.01 | |
| 54 | Җөмләнең иярчен кисәкләре. Хәлләр (шарт, кире). | Яңа материалны өйрәнү | | Күнегүләр өстендә эш | Шарт, кире хәлләрнең җөмләдә белдереп килүләре. Җөмләдә кулланылышлары, схемалар төзү. | 1 | 22.01 | |
| 55 | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре . Тиңдәш ияләр, тиңдәш хәбәрләр. | Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру | модельне тулыландыру һәм аны уку | | Җөмләнең тиңдәш кисәкләре турында белемнәрне системалаштыру | 1 | 26.01 | |
| 56 | Тиңдәш һәмтиңдәш булмаган | Белем һәм | модельне | 293 күнегү | Тиңдәш кисәкләр | 1 | 27.01 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аергычлар, тәмамлыклар, хәлләр | күнекмәләрне системалаштыру | тулыландыру һәм аны уку | буенча модель төзү | янында тыныш билгеләре турында белемнәрне системалаштыру | | | |
| **V** | **Фонетика. Орфоэпия һәм орфография (17)** | | | | | | | |
| 57 | Хәтер диктанты. Фонетика һәм орфоэпия турында гомуми төшенчә. Аваз. Фонема. Авазлар һәм хәрефләр. Сөйләм органнары, аларның авазларны ясауда катнашуы. Авазларның ясалышы | Яңа белем үзләштерү | Модель төзергә өйрәнү | Махсус күнегүләр | Сөйләм органнары һәм аларның авазлар ясаудагы роле | 1 | 29.01 | |
| 58 | **БСҮ. Сочинение язу .** “Кышкы төн” | Сөйләм үстерү дәресе | План төзергә | Сорау-җавап эше | Фикер йөртү, план төзү, күз алдына китерү | 1 | 02.02 | |
| 59 | Сузык һәм тартык авазлар. Татар телендә сузык авазлар, аларның саны. Сузык авазларны төркемләү. Сузык авазлар һәм аларның составы | | Модель төзергә өйрәнү | Сораулар | Сузык һәм тартык авазлар турындагы белемнәрне актуальләштерү | 1 | 03.02 | |
| 60 | Тартык авазлар һәм аларның составы. Тартык авазларны төркемләү. Тартыклар таблицасын төзү | Катнаш | Таблица төзү | | Тартык авазларны искә төшерергә, характеристика бирергә | 1 | 05.02 | |
| 61 | Графика һәм орфография турында гомуми төшенчә. Авазларны язуда күрсәтү. Алфавит. | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Язма эш | Сузык авазлар аларның әйтелеш үзенчәлекләре турында төшенчә формалаштыру | 1 | 09.02 | |
| 62 | Кабатлау, ныгыту. | Кабатлау дәресе | Модельне файдалану | Практик эш | Практик эшләр, белемнәрне гомумиләштерү, транскрипция белән эшләү. | 1 | 10.02 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 63 | Сингармонизм законы, аның төрләре. Татар телендә сузыклар кыскару күренеше. | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Гамәли эшләр | Сингармонизм төшенчәсе. Аның 2 төре | 1 | 12.02 | |
| 64 | Рәт гармониясе | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Контроль бирем | Рәт гармониясе турында белем үзләштерү | 1 | 16.02 | |
| 65 | Ирен гармониясе | Яңа белем үзләштерү | | Контроль күнегү | Ирен гармониясе турында белем үзләштерү | 1 | 17.02 | |
| 66 | **БСҮ. Контроль изложение.** | Сөйләм үстерү дәресе | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш (“Бездәге яз башка шул” Хари сова Ч.М., 2012, 187 б.) | Ишеткәнне текстка якын итеп, эзлекле рәвештә язу күнекмәсе | 1 | 19.02 | |
| 67 | **Контроль изложениены язу.** | Сөйләм үстерү дәресе | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш | Ишеткәнне текстка якын итеп, эзлекле рәвештә язу күнекмәсе | 1 | (23) 24.02 | |
| 68 | [к], [г] һәм [къ],[гъ] тартыклары | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү һәм аны уку | Бирем | Авазларның ясалу урыны буенча аер-масы. [к], [г] һәм [къ],[гъ] тартыкларын аеру күнекмәсе фор-малаштыру | 1 | 26.02 | |
| 69 | [н] һәм [ң]тартыклары. Җ һәм й, х һәм h, н һәм ң авазларын белдерүче хәрефләрнең дөрес язылышы. | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Контроль күнегү | Авазларның ясалу урыны буенча аермасы. Бу авазларның охшаш һәм аермалы якларын чагылдырган модель төзү | 1 | 02.03 | |
| 70 | [w] һәм [в] тартыклары . **Сүзлек диктант.** | катнаш | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Темага караган бирем | Авазларның ясалу урыны буенча аермасы. Бу | 1 | 03.03 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | авазларның охшаш һәм аермалы якларын чагылдырган модель төзү | | | |
| 71 | Эш кәгазьләре: мәкалә язу. | Сөйләм үстерү дәресе | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Мәкалә язу тәртибен тикшерү | мәкалә язарга өйрәнү | 1 | 05.03 | |
| 72 | Сөйләмдә тартыкларның үзгәреше | Яңа белем үзләштерү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Теорияне тикшерү | Тартыкларның үзгәреше: охшашлану, охшашсызлану, җайлашу турында төшенчә | 1 | (9) 10.03 | |
| 73 | **БСҮ. Изложение язу.** | | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | | Ишеткәнне текстка якын итеп, эзлекле рәвештә язу күнекмәсе | 1 | 12.03 | |
| 74 | **БСҮ. Изложение язу. “Сөйләм”** | Сөйләм үстерү дәресе | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш | Ишеткәнне текстка якын итеп, эзлекле рәвештә язу күнекмәсе | 1 | 16.03 | |
| 75 | Е, ё, ю, я хәрефләренең дөрес язылышы | Яңа белем үзләштерү | Модель төзергә өйрәнү | Күнегүләр эшләү, биремнәр | Е,ё,ю,я хәрефләренең дөрес язылышы турында белем фо-малаштыру | 1 | 17.03 | |
| 76 | Ь һәм ъ хәрефләренең дөрес язылышы. Аваз белдерми торганнары. **Сүзлек диктант** | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Орфогра фик сүзлек белән эш | Ь – нечкәлек билгесе, ъ – калынлык билгесе. Аларның вазифалары турында төшенчә | 1 | 19.03 | |
| 77 | Кабатлау. Ныгыту дәресе. | | системалаштыру | Күнегүләр өстендә эш, тест эшләү | Транскипцияне яхшы белү, авазларның язуда бирелеше. | 1 | 02.04 | |
| 78 | Сүзләргә фонетик | Белем һәм | Фонетик анализ ясау | Фонетик | Сүзләргә фонетик | 1 | 06.04 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | анализ ясау | күнекмәләрне системалаштыру | тәртибен язу | анализ | анализ ясау | | | |
| **VI** | **Лексикология һәм сөйләм культурасы (16)** | | | | | | | |
| 79 | Лексикология һәм сөйләм культурасы. Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Сораулар | Лексикология, сөйләм культурасы турында төшенчә. | 1 | 07.04 | |
| 80 | **БСҮ. Изложение язу “Лексикология** | Сөйләм үстерү дәресе | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Язма эш “Мин шулар турында уйладым” Харисова Ч.М., 2012, 187 б. | Бөйләнешле сөйләм үстерү | 1 | 09.04 | |
| 81 | Хаталарны төзәтү өстендә эш. Сөйләм культурасы. Икетеллелек. | Яңа белем формалаштыру | Алган белемнәрне ныгыту | Биремнәр үтәү, теория | Сөйләм культурасы. | 1 | 13.04 | |
| 82 | Бер һәм күп мәгънәле сүзләр. | Яңа материалны өйрәнү | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Күнегүләр өстендә эш, сорау ларга җавап | Сүзләрнең бер һәм күп мәгънәле булулары. Полисемия күренеше. | 1 | 14.04 | |
| 83 | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәләре. | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Сүзлек белән эш, биремнәр | Сүзләрнең туры һәм күчерелмә мәгънәдә булулары. Метафора күренеше. | 1 | 16.04 | |
| 84 | Омонимнар һәм аларның төрләре. | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Күнегүләр өстендә эш, тест эшләү | Омоним. Омонимнарның төрләре турында төшенчә. Саф лексик, омофоннар, омографлар, омоформалар турында мәгълүмат. | 1 | 20.04 | |
| 85 | Синонимнар | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Күнегүләр өстендә ш. | Синонимнар, доминанта, | 1 | 21.04 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | “Синоним нар сүзле ге” белән эшләү. | синонимик оя төшенчәләрен аңлау. | | | |
| 86 | Антонимнар | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | “Антоним нар сүзлеге” белән эшләү | Антонимнар. Даими яки текстуаль антонимнар. | 1 | 23.04 | |
| 87 | **Хәтер диктанты** | Сөйләм үстерү дәресе | Белемнәрен системалаштыру | | Хәтерләрен яңарту. | 1 | 27.04 | |
| 88 | Хаталар өстендә эш. Фразеологик әйтелмәләр, аларның мәгънәсе. Фразеологизмнарн ың сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре. | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу, модель төзү | Сүзлек белән эш | Фразеологик әйтелмә төшенчәсе. Аның мәгънәсен аңлату | 1 | 28.04 | |
| 89 | Татар теленең килеп чыгышы ягыннан сүзлек составы: татар теленең үз сүзләре һәм башка телләрдән алынган сүзләр. Төрки –татар сүзләре һәм алынмалар. | Яңа белем формалаштыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Күрмә диктант | Алынма сүзләр турында төшенчә. Гомумтөрки сүзләр. Гарәп, фарсы, грек, немец сүзләре. | 1 | 30.04 | |
| 90 | **БСҮ. Сочинение язу. “Яхшылык эшләсәң – дәшмә, бүтәннәр сөйләсеннәр ”** | Сөйләм үстерү дәресе | Сөйләм эшчәнлеген үстерү | Гади план төзү күнек мәләрен ныгыту | Сочинение язу, план төзү, әэгәмә, сорауларга җавап, сүзләр өстендә эш | 1 | 04.05 | |
| 91 | Татар теленең кулланылыш өлкәсе ягыннан сүзлек составы. Гомумхалык сүзләре, әдәби телсүзләре, диалекталь сүзләр. | Яңа материалны өйрәнү | Сүзлек белән эш | Күнегүләр өстендә эш | Гомумхалык сүзләре белән танышу. Диалекталь сүзләрне өч диалектка бүлү. | 1 | 05.05 | |
| 92 | Татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составы. | Яңа белем формала штыру | Укытучы сөйләгәнне зиһенгә алу | Күнегүләр эшләү | Татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составы. Тарихи сүзләр һәм архаизмнарны | 1 | 07.05 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | таный белү | | | |
| 93 | Лексика,<br>архаизмнар,<br>неологизмнар.<br>Искергән сүзләр,<br>тарихи сүзләр<br>**Сүзлек диктанты** | Яңа белем<br>формала<br>штыру | | Күнегүләр<br>өстендә эш | Лексика,<br>архаизмнар,<br>неологизмнар.<br>Искергән<br>сүзләр, тарихи<br>сүзләр | 1 | 11.05 | |
| 94 | Эш кәгазьләре: хат,<br>белешмә язу. | Яңа белем<br>формала<br>штыру | Хат язу | Хат, белеш<br>мә язу<br>тәртибен<br>тикшерү | Хатларның<br>төрләрен аеру | 1 | 12.05 | |
| 95 | Татар теленең төп<br>сүзлекләре, аларны<br>куллана белү. | Яңа белем<br>формала<br>штыру | Укытучы<br>сөйләгәнне<br>зиһенгә алу,<br>модель төзү,<br>Күнегүләр<br>эшләү | Контроль<br>күнегү | Аңлатмалы һәм<br>орфографик<br>сүзлекләр<br>турын-да төшенчә.<br>Сүзлекләрнең<br>төрләре<br>турында белешмә<br>булдыру.<br>Лексикология<br>турында<br>кабатлау.<br>Сүзләргә лексик<br>анализ<br>ясау | 1 | 12.05 | |
| 96 | Лексикология<br>бүлеген кабатлау. | Катнаш | Грамоталылык<br>дәрәҗәсен тикшерү | Тестлар<br>эшләү | Белемнәрне<br>гомумиләштерү | 1 | 14.05 | |
| 97 | Сүзләргә лексик<br>анализ ясау. | Яңа белем<br>формала<br>штыру | Укытучы<br>сөйләгәнне<br>зиһенгә алу,<br>модель төзү,<br>Күнегүләр<br>эшләү | контроль<br>күнегү | Аңлатмалы һәм<br>орфографик<br>сүзлекләр<br>турында төшенчә.<br>Сүзлекләрнең<br>төрләре<br>турында белешмә<br>булдыру.<br>Лексикология<br>турында<br>кабатлау.<br>Сүзләргә лексик<br>анализ | **1** | 14.05 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | ясау | | | |
| **98** | **БСҮ. Грамматик биремле контроль диктант** | Контроль диктант | Еллык үтелгәнне һәм грамоталылык дәрәҗәсен тикшерү максатында. | Контроль диктант язу, калли график кагыйдәләрне кисәтү. | Грамматик биремле диктант | 1 | 18.05 | |
| **VII** | **Уку елы дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** | | | | | | | |
| 99 | Хаталар өстендә Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. Морфология. | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Мөстәкыйль эш | 1 | 19.05 | |
| 100 | Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. Синтаксис һәм пунктуация | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Мөстәкыйль эш, тест буенча эш | 1 | 25.05 | |
| 101 | Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. Фонетика, орфоэпия, орфография. | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Мөстәкыйль эш, фонетик анализ, сүзлек диктанты | 1 | 25.05 | |
| 102 | Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. Лексикология һәм сөйләм культурасы. Сүз ясалышы һәм сүз төзелеше. | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Мөстәкыйль эш, | 1 | 26.05 | |
| 103 | Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне гомумиләштереп кабатлау. | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Мөстәкыйль эш, сүз төзелешен тикшерү | 1 | 26.05 | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сүз ясалышы һәм сүз төзелеше. | | | | | | | |
| 104 | Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне йомгаклау. | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Тест | 1 | 28.05 | |
| 105 | Уку елы дәвамында өйрәнгәннәрне йомгаклау. | Кабатлау дәресе | Белемнәрне системага сала белү, үзбәя, үзконтроль күнекмәләрен ныгыту. | Кабатлау, күнегүләр , тестлар эшләү | Тест | 1 | 28.05 | |